**СОВЕТ**
**Кулегашского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Күләгәш авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28.12.2018 Күләгаш авылы № 44-3

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгаш авыл җирлеге Советының «Җир салымы турында»гы 2017 елның 20 ноябрендәге 30-2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»

Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге, 1998 елның 29 июлендәге «Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында»гы 135-ФЗ номерлы Федераль закон, Күләгаш авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгаш авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгаш авыл җирлеге Советының 2017 елның 20 ноябрендәге 30-2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**2 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

"Шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык, яшелчәчелек яки терлекчелек, шулай ук дача хуҗалыгы өчен сатып алынган (бирелгән) 0,3 % ;»

**2 пунктның 8 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

"Оборона, куркынычсызлык һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештәге чикләнгән 0,3% ;»

**2 Пунктка түбәндәге эчтәлектәге 9 абзац өстәргә:**

«Башка җир өлешләренә карата-1,45 %».

**3 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«-I һәм II төркем инвалидлар, балачактан инвалид һәм инвалид балаларга торак фонды тарафыннан алынган җир участоклары, шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык, яшелчәчелек яисә терлекчелек, шулай ук дача хуҗалыгы алып бару өчен бирелгән җир, милектә булган, даими (срогы чикләнмәгән) файдалану яисә гомерлек мирас итеп файдалану өчен бирелгән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләр;»

**6 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә::**

"Шул ук вакытта Салым түләүче оешмалар өчен салым түләү срогы Салым кодексының 398 статьясындагы 3 пунктында каралган срок элегрәк билгеләнергә тиеш түгел. Салым түләүче физик затлар тарафыннан узган салым чорыннан соң килүче елның 1 декабреннән дә соңга калмыйча түләнергә тиеш.».

2. Әлеге карар 2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Күләгаш  авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына куярга, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләр порталы составындагы Әгерҗе муниципаль районы сайтына agryz.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталына pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Күләгаш  авыл җирлеге Советының Финанс-бюджет, социаль Законлылык һәм хокук тәртибе комиссиясенә йөкләргә.

Совет рәисе,
авыл җирлеге Башлыгы Ю.Н. Васильев